**Класс:** 4
**Укытучы:** Касыймова Зөһрә Илсур кызы
**Тема**: Мастер-класс: табигый материал белән эш ( ком белән рәсем ясау)
**Максаты**: ком һәм аның үзлекләре турындагы белемнәрне камилләштерү, табигый материал (ком) белән эшләү алымнарын һәм күнекмәләрен ныгыту; укуга һәм иҗат итүгә теләк тәрбияләү

**Материал:** ком, җилем, өлге (рәсем), ак кәгазь, пумала, чүпрәк

**Дәрес барышы:**

**-Хәерле көн, укучылар! Бүгенге минем мастер-класс сезгә кызыклы һәм файдалы булыр дип өметләнеп калам. Барыбызга да уңышлар телим.**

**-Бүгенге дәрестә без сезнең белән ком белән рәсем ясарбыз. Ә нәрсә соң ул ком? Ул нинди үзлекләргә ия?**

**<u>Слайд 2</u>** Җир кабыгының өске өлешләрендә очрый торган каты минералларның вак кына бөртекләре. Табигый ком төрле минераллар кергән көпшәк бөртекләр катнашмасыннан тора.

Тәрҗемәләре:

-песок (рус теле)

-sand (инглиз теле)

**-Эшебезне башлыйбыз. Моның өчен безгә**

**-А4 форматындагы кәгазь,**

**-гади һәм төсле ком,**


**-җилем,**

**-пумала,**

**-өлге кирәк булачак.**

***Беренчел итеп без өлгене әзерлибез.**

**<u>Слайд 3</u>** Әлеге өлгедә пирамидалар ясалган. Пирамида –ул борынгы Мисыр фиргавеннәренең каберләре өстенә төзелгән, шул формадагы гаять зур таш корылма. (*Бу турыда без “Эссе чүлдә” дәресендә сөйләшеп үткән идек.)



*Алга таба, җилемне алып, рәсемнең контурын (кырыен) йөртеп чыгабыз.

* Киләсе эш итеп, җилемгә төсле комны сибеп чыгабыз.

*Чиста кәгазь битенә артык комны коеп төшерәбез. Ярдәмгә пумала килә.

* Рәсемнең бар җирен дә шулай итеп ком белән каплыйбыз.

Безнең рәсем әзер. Бүгенге дәрестән үзегезгә күп яңалыклар алгансыз дип өметләнәм. Сау булыгыз!